РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** Буа шәһәре **КАРАР**

05.06.2026 № 8-13

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2015 елның 15 августындагы 12-50 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарын үз көчен югалткан дип тану турында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 281 статьясы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы (28.12.2025 редакциясендә), «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы (28.12.2025 редакциясендә) федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Уставы белән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2015 елның 15 августындагы 12-50 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына керүче зат, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында районның рәсми сайтында http://buinsk.tatarstan.ru. урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р. Камартдинов